СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**«04» октябрь 2016 ел** **№23**

## Утар-Аты авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

### Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 20 ноябренә Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2017 елда Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 150 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

- авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту.
- юлларга вак таш салу. :

Утар Аты авылы: 9 Май ур., Совет ур., Комсомол ур., Мәктәп ур., Кооператив урамы.

Субаш Аты авылы: Кооператив ур., Яңа ур., 9 Май ур., Тарлау ур.

Орнашбаш авылы, Мичурин ур., Зеленая ур., механизаторлар ур., Тукай ур., Клуб урамы, Яшьләр урамы, Комсомол урамы.

Югары Аты авылы: Кооператив урамы, Комсомол урамы, Мәктәп урамы.

Иске Җөлбә авылы, Үзәк ур., 9 Май ур.
Кушлавыч авылы, 8 Март ур. - җәяүлеләр күперләрен ремонтлау;:
Орнашбаш, Утар Аты, Кушлавыч авыллары.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе                                        юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга. http:pravo.tatarstan.ru) гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында мәгълүмат: Утар-Аты авылында (мәдәният йорты, китапханә бинасы, муниципаль берәмлекнең административ бинасы), Орнашбаш авылында (авыл клубы, китапханә бинасы); Кушлавыч авылында (китапханә, мәктәп бинасы).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Утар-Аты авыл
җирлеге башлыгы                                        А.Г.Хәкимҗанов

СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012621